| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Олы Кайбыч ав. № 518

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 февралендәге 64 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карары нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 февралендәге 64нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага кертелгән гражданнар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров